**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«02» 03 2026 ел Яр Чаллы №641

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше комиссиясен төзү турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карарын раслау хакында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Башкарма комитетның 2022 елның 14 мартындагы 700 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше комиссиясен төзү турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карарын расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше комиссиясен төзергә һәм аның составын 1 кушымта нигезендә расларга.
3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше комиссиясе турында нигезләмәне 2 кушымта нигезендә расларга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Җитәкче урынбасары Д.Ф. Вәлиуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 02.03. 641 номерлы карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше комиссиясе составы

Комиссия рәисе:
Маняпов Линар Нурислам улы – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе.

Комиссия рәисе урынбасары:
Вәлиуллин Динис Фәнис улы – Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары.
Комиссия секретаре:
Сәйфуллина Язилә Илсур кызы – Башкарма комитетның төзелеш һәм яшәешне тәэмин итү секторы белгече, комиссия секретаре.

Комиссия әгъзалары:
1. Галимова Гөлнара Әзһәт кызы – Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары.
2. Минимуллин Илдар Мөнәвир улы – Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе.
3. Әһлиуллина Рәисә Мансур кызы – юридик бүлек башлыгы.
4. Исхакова Гөлназ Гаяз кызы – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы.
5. Хайбуллин Ленар Радикович – Начальник управления Ветеринарного объединения Тукаевского муниципального района.
6. Галиуллина Айсылу Сабит кызы – Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.
7. Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Яр Чаллы шәһәрендәге, Актаныш, Тукай, Мөслим, Минзәлә районнарындагы территориаль бүлеге вәкиле (килешү буенча).
8. «Сетевая Компания» ААҖ вәкиле (килешү буенча).
9. Район газ хезмәте вәкиле (килешү буенча).
10. Җирле коммуналь челтәрләр вәкилләре (килешү буенча).
11. Авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча).

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 02.03. 641 номерлы карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше комиссиясе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше комиссиясе (алга таба — Комиссия) муниципаль район территориясендә шәһәр төзелеше нормативларын булдыру, эзлекле камилләштерү һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен төзелә.

1.2. Комиссия даими эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм үз эшен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә гамәлгә ашыра.

## 2. Комиссиянең төп функцияләре

2.1. Мөрәҗәгатьләр, Россия Федерациясе законнары нормаларын исәпкә алып, эскиз проектын, генераль планны, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен, шәһәр төзелешен проектлау нормативларын, территорияне планлаштыру документларын, территориядән файдалануның башка чикләүләрен кертеп, территориянең архитектура-шәһәр төзелеше потенциалын бәяләү максатында карала.

2.3. Реклама конструкциясен (элмә такталар, панель-кронштейннар, билбордлар, күләмле якты хәрефләр, баннерлар, пилоннар, реклама стелалары, медиаэкраннар, яктылык тартмалары һ.б.) урнаштыруга рөхсәт бирү турында кызыксынган затларның гаризаларын карау.

2.4. Бинаның архитектура концепциясен килештерү турында кызыксынган затларның гаризаларын карау.

2.5. Территорияләрне планлаштыру һәм ызанлау проектларын килештерү турында кызыксынган затларның гаризаларын карау.

2.6. Биналарның архитектура - шәһәр төзелеше күренешләрен килештерү турында кызыксынган затларның гаризаларын карау.

## 3. Комиссия составын төзү тәртибе

3.1. Комиссия составы, саны, аның персональ составына кертелә торган үзгәрешләр Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән раслана.

3.2. Комиссия составына башка оешма вәкилләре дә кертелергә мөмкин (кирәк булганда).

## 4. Комиссия хокуклары

4.1. Комиссия хокуклы:

- мөрәҗәгать итүчеләрдән тиешле дәүләт күзәтчелеге органнарының өстәмә документларын, махсуслаштырылган оешмаларның карар кабул итү өчен кирәкле бәяләмәләрен соратып алырга;
- район җирле үзидарә органының структур бүлекчәләреннән Комиссиягә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бәяләмәләрне, башка материалларны соратып алырга;
- дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән Комиссия утырышларында карала торган мәсьәләләргә кагылышлы бәяләмәләр, башка материаллар соратып алырга;
- Комиссия тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча материалларны анализлау һәм тиешле тәкъдимнәр әзерләү өчен, бәйсез экспертларны җәлеп итәргә;
- Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә Комиссия компетенциясенә кергән һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карарын таләп итә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә;
- Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә Комиссиянең персональ составын үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертергә.

4.2. Комиссия гаризаны караудан баш тартырга хокуклы:

- документларның тулы пакеты булмаганда;
- әлеге карарның 2 пункты 2.5, 2.6 бүлекләрендә күрсәтлгән документларны килештергәндә, җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалану төре туры килмәгән очракта.

## 5. Эш тәртибе

5.1. Комиссия утырышлары кирәк булган саен уздырыла. Комиссия утырышы датасы һәм вакыты турында карарны Комиссия рәисе яисә аның кушуы буенча Комиссия рәисе урынбасары кабул итә.

5.2. Комиссия утырышлары көн тәртибе нигезендә уздырыла.

5.3. Көн тәртибе Комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан төзелә, Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан раслана.

5.4. Көн тәртибе Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышы көненә кадәр 2 (ике) эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

5.5. Комиссия әгъзалары карар проектына кертү өчен, Комиссия утырышы датасына кадәр 2 (ике) эш көненнән дә соңга калмыйча, Комиссиянең җаваплы секретарена тәкъдимнәр тапшырырга хокуклы.

5.6. Комиссия утырышларында Комиссия әгъзалары катнаша.

5.7. Комиссия утырышын Комиссия рәисе, ә Комиссия рәисе булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

5.8. Комиссия утырышында беркетмә алып барыла, анда көн тәртибендәге һәр мәсьәлә буенча карар язылa, ул Комиссия утырышыннан соң 10 (ун) эш көне эчендә Комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан рәсмиләштерелә.

Беркетмә проекты Комиссия утырышында рәислек итүчегә имза кую өчен җибәрелә.